РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«12» декабрь 2022 г. Олы Кайбыч ав. № 162

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына (2020 елның 23 сентябрендәге 5 номерлы , 2021елның 28 декабрендәге 96 номерлы, 2022 елның 11 июлендәге 127 номерлы, 2022 елның 30 августындагы 145 номерлы, 2022 елның 11 ноябрендәге 154 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының бер тапкыр күләмендә исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладычы күләме 12 688 сум тәшкил итә.».

1.2 нче кушымтаның 5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасын муниципаль хезмәт вазыйфасына азрак вазыйфаи окладлы белән биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына стандарты кертелүгә бәйле рәвештә үзгәртеп

корганда билгеләнү очрагы керми, мондый очракта акчалата бүләкләү күләме муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен элек биләгән вазыйфасы буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне исәпкә алып башкарыла;»;

1.3. 1 нче кушымтаның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Муниципаль районнарның, шәһәр округларының, авыл һәм шәһәр җирлекләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш, түләү өчен түбәндәге акчалар каралган (бер елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) класслы чин өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү - вазыйфаи окладларның ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 18 процентыннан артмаган күләмдә;

7) норматив каралмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык хезмәт хакына айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.».

1.4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы, Башлык урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» нигезләмәгә 6 нчы кушымтаны яңа редакциядә 2нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2022е. «12» 12
162 номерлы карарына 1нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына, Башлык урынбасарына, Контроль-хисап палатасы рәисенә айлык өстәмә акчалата түләүләр күләме**

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 33592 |
| Башлык урынбасары | 30233 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 30233 |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2022е. «12» 12
162 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» нигезләмәгә 6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгына, Башлык урынбасарына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, Башкарма комитет җитәкчесенә айлык өстәмә акчалата түләүләр күләме**

| Вазыйфа исемнәре | Айлык акчалата түләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 80942 |
| Башлык урынбасары | 38975 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 16213 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 22299 |